ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**«15» ноябрь 2021 ел** **№18**

**Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль мәгълүмат системаларының эшләү һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 28 декабрендәге 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2019 елның 21 августындагы 11 номерлы үзгәрешләр белән)**

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясына, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә төбәк һәм муниципаль мәгълүмат системаларына бердәм таләпләр турында» 2013 елның 28 ноябрендәге 1091 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән тәңгәлләштерү максатында Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль мәгълүмат системаларының эшләү һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 27 декабрендәге 39 номерлы карарына (2019 елның 21 августындагы 63 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Әлеге Нигезләмәнең 3.7. пунктында күрсәтелгән мәгълүмат системаларын, электрон мәйданчыкларны интеграцияләү бердәм мәгълүмат системасы ярдәмендә түбәндәгечә башкарыла:

1) күрсәтелгән системаларның, электрон мәйданчыкларның үзара хезмәттәшлеге турында электрон документлар һәм мәгълүмат алмашу, анда 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда каралган электрон документларны һәм мәгълүматны имзалау һәм урнаштыру, шул исәптән «Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән региональ мәгълүмат системаларын кулланып, бердәм мәгълүмати системага гарантияләнгән тапшыруны тәэмин итә торган бердәм мәгълүмат системасы белән. Бердәм мәгълүмат системасында электрон документлар һәм мәгълүмат урнаштыру өчен әлеге Федераль законда каралган срокларны исәпләү аларны бердәм мәгълүмат системасында урнаштырганнан соң башлана;»;

2) әлеге мәгълүмати системалардан, электрон мәйданчыклардан, бердәм мәгълүмат системасының мәгълүматлар базаларыннан файдаланып;

3) әлеге системаларда эшкәртелә торган мәгълүматка карата бердәм технологик

һәм лингвистик таләпләрне билгеләп;

4) сатып алулар турында мәгълүматны рәсми сайтта урнаштырып.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: http://arsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы Габделхаков В.Р.